БЕЗНЕҢ ИШЕГАЛДЫ
Президент программасы буенча республикада 6923 ишегалды төзекләндерелгән

> 2

МОГҖИЗА КӨТКӘНДӘ
«Бердәм Россия»нең Татарстандагы бүлеге «Теләкләр чыршысы» хәйрия акциясенә кушылды

> 2

АЯЗ ШӘФИГУЛЛИН:
«Төп бурыч – кечкенә авылларны бетермәү»

> 3

ШӘЛ БӘЙЛӘДЕМ
Илшат Заһидуллинның бу эш белән шөгыльләнүенә – 40 ел

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 183 (28765) | Чәршәмбе | 15 декабрь | 2021 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

Берәүнең дә үзенә уңайлы булган мохиттән аерыласы, чикләнәсе килми, әлбәттә. Хәтта ул чикләүләрнең вакытлыча, аларның киләчәк өчен әһәмиятле булуын белә торып та. Коронавирусны вазгыять белән дә шулай ук. Элеккеге саннар шом салса да, хәзергесе өмет чаткысы өсти. Белгечләр Татарстанда авыручылар санының кимүе турында әйтә. Озаккамы, вакытлычамы – анысы билгесез. Хәер, анысы да үзебездән тора.

Татарстан QR-кодлы тормышта октябрьдән бирле яши. 22 ноябрьдән исә ансыз җәмәгать транспортына да кертми башладылар. Чикләү катгый, җитди, күпчелекне канәгатьләндерми торганнардан, әмма кирәкле иде. Моны республика җитәкчелеге дә кат-кат искәртте. Нәтиҗәсе – күз алдында. Һәрхәлдә, аны сәламәтлек саклау тармагы яхшы тоя.

Чикләү чаралары кертелгәнче, авыручылар санының атналык үсеше 19 процентны тәшкил иткән иде. Әйтик, 19 ноябрьдә коронавирус белән авыручылар бер тәүлеккә 267 кеше булса, 23 көннән соң сырхаулар саны кими башлады. Үткән атнада чирләүчеләр кимү күрсәткече исә 8 процентка җиткән. Узган тәүлектә 179 яңа очрак теркәлгән иде. 200 белән 100 арасы сизелерлек, әлбәттә.

Аз булса да, медицина хезмәткәрләренә тын алу мөмкин булды. Әлбәттә, эшсез торганнары юк. Тик сырхауларның өермә булып килмәүләре дә куандыра инде. Коронавирус кына түгел, башка чирләр дә юкка чыкмады бит. Табибларның игътибарын шуларга юнәлтерлек мөмкинлеге барлыкка килде. Ятаклар бушый, бүлекләр яңадан элеккечә хезмәт күрсәтергә алына.

Әйтик, Чаллының 5 нче шәһәр хастаханәсе коронавируслы сырхауларны кабул итүдән туктаган. Хәзер медицина оешмасы элеккечә эшли. Әмма хастаханә, вазгыять тискәре якка үзгәреп, сырхаулар саны кабат артса, «таҗлы» статусына яңадан кайтырга әзер. Июнь аеннан башлап хастаханә коронавирус йоктырган 9,5 меңләп сырхауны кабул иткән. Барлыгы 380 урынга исәпләнгән хастаханәгә кайчагында 500ләп кешене дәваларга туры килгән. Хәзер инде өстәмә ятаклар булдырасы юк.

Илдар Мөхәммәтҗанов

QR ЧИРНЕ КУА

«ВТ» хәбәрчесенә килеп ирешкән мәгълүматлар буенча, хәзерге вакытта Республика клиник хастаханәсендә коронавирус йоктырган 217 кеше дәвалана. Тәүлек эчендә 38 кешене салганнар. Реанимация һәм интенсив терапия бүлегендә 24 кеше ята, шуларның 13е үпкәне ясалма вентиляцияләү аппаратына тоташкан.

Республика клиник хастаханәсенең вакытлыча ачылган йогышлы авырулар госпитале җитәкчесе урынбасары Сәяр Сиражетдинов та чикләүләрнең уңай ягы булды дип ышана.

– Табиблар үз эшләреннән чыгып бәя бирә инде. Чикләүләр булышты. Хәтерләсәгез, кабул итү бүлегенә көненә берничә йөздән артык кеше мөрәҗәгать итә иде. Хәзер исә бу сан сизелерлек кимеде. Табиблар үз профильләренә бәйле эшчәнлеген алып бара ала. Саннар һәм хастаханәдәге вазгыять үзгәреш турында сөйли. Әлбәттә, тик торганыбыз юк, әмма тынычлап эшли алабыз, – ди табиб.

Сүз уңаеннан, Урал һәм Көньяк федераль университетлары галимнәре Россия төбәкләренең пандемия шартларында яшәешен тикшергән. Фәнни хезмәткәрләр ачыклаганча, Татарстан, Башкортстан, Ростов, Түбән Новгород һәм Самара өлкәләре – пандемия башында авырлыклар белән очрашса да, вакыт узу белән, катлаулы шартларга күнеккән төбәкләр исемлегендә. Белгечләр сүзләренчә, пандемия аркасында икътисади хәле тотрыклы булмаган, шәһәрдә яшәүче халык өлеше күп, кече һәм урта эшмәкәрлек тармагы үсеш алмаган төбәкләр аеруча зыян күргән. Воронеж, Волгоград, Чиләбе, Омск өлкәләре, Красноярск крае исә коронавирус котырган чорда авырлык кичермәгән.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

САН

Татарстан Россия төбәкләре арасында коронавируска каршы вакцина ясату буенча 6 нчы урынны били. Элегрәк ул 64 нче урында иде.
Соңгы мәгълүматлар буенча, республикада вакцина ясатучылар саны 2231564 кешегә җиткән. 1857452се прививканың икенче дозасын алган.

47 гаиләдә – өй туе

Быел республикада күпбалалы 47 гаилә дәүләттән яңа фатир (барлыгы 4,5 мең кв. м мәйданда) алган. Торакны Татарстан Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды «Торак һәм шәһәр мохите» илкүләм проекты буенча төзегән. Күпбалалы кайбер ата-аналар берьюлы берничә торакка ия булган. Мәсәлән, Бөгелмә районында яшәүче 9 балалы гаилә өч фатир: берәр бүлмәле – 2 һәм өч бүлмәле 1 фатир алган. Дәүләт биргән бушлай фатир яшәү өчен тулысынча әзер: ремонт ясалган, сантехника, исәпләгечләр, электр һәм газ плитәләре урнаштырылган.

Сүз уңаеннан, күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү программасында әти-әниләре белән бергә яшәүче биш һәм аннан күбрәк балалы гаиләләр катнаша.

Вузга кергәндә үзгәреш булачак

Югары уку йортларына кергәндә, чыгарылыш сыйныф укучыларының портфолиосы БДИ нәтиҗәләрен алыштырырга мөмкин. Бу хакта Рособрнадзор башлыгы Анзор Музаев «Российская газета» хәбәрчесенә белдергән. Музаев әйтүенчә, балалар инде 6 нчы сыйныфтан башлап үзләренең уңышлары турында мәгълүматлар җыячак һәм волонтерлык, спорт һәм иҗат белән шөгыльләнгән өчен баллар туплаячак. Бу аларга вузга керү хокукы бирәчәк. Җитәкче билгеләп үткәнчә, әлегә 9–11 нче сыйныф укучылары гына портфолио булдыру белән кызыксына. Музаев сүзләренә караганда, министрлыкта бу өметле тәкъдим буларак бәяләнә.

Исегезгә төшерәбез: ноябрь аенда Россия тикшерү комитеты җитәкчесе Александр Бастрыкин, БДИне бетереп, Советлар Союзы чорындагы мәгариф системасын торгызырга тәкъдим итте. Рособрнадзорда әйтүләренчә, бу җәһәттән конкрет тәкъдимнәр көтелә.

Көн кадагында

Плитә өй җылыту өчен түгел

Кыш башланганнан бирле инде өченче фаҗига. Дүшәмбе Казанның Һади Такташ урамындагы йортларның берсендә сөрем газы белән агуланган ике ир-ат гәүдәсе табылган. Аларның берсе фатирда чакта ук җан биргән булган. Икенчесенең гомере өчен табиблар көрәшә.

Хәтерләсәгез, әле декабрь башында гына Казанның Короленко урамындагы фатирларның берсендә сөрем газы белән агулану аркасында бер ир белән хатынның гомере өзелгән иде. Берничә көн элек Бөгелмәдә дә шундый хәл булды. Ни кызганыч, кыш көне елның-елында шундый фаҗигаләр күзәтелеп тора. Сөрем газы дигән мәкерле дошман корбаны булмас өчен, нинди кагыйдәләрне истә тотарга кирәк?

Казанның Идел буе районында газчы булып хезмәт күрсәтүче Хәниф Гарипов сөрем газы белән агулану очраклары күбрәк кешенең газга, газ җиһазларына салкын каравы аркасында килеп чыга дип саный.

– Газ җиһазларын тикшерергә кергәндә барлык куркынычсызлык кагыйдәләрен аңлатабыз. Берсендә берәүләрнең газ конфоркасын ачып куеп, өй җылыткан чагына туры килдем. Болай эшләүнең куркыныч икәнен дә беләләр. «Ул арада гына зыян булмас дип уйладык», – диде хуҗа кеше. Араларында йортына газчыны бөтенләй кертмәүчеләр дә бар. Югыйсә бу безгә түгел, аларның үзләренә кирәк, – ди тәҗрибәле газчы.

Хәниф Гарипов кыш көне төтен-җилләткеч юлларының төзеклеген даими рәвештә тикшереп, аларны чистартып торырга куша. «Алар аша һава йөрүен тикшерү өчен, рәшәткәгә кәгазь куеп карарга кирәк. Ул анда ябышырга тиеш. Бүлмәләрне, бигрәк тә аш бүлмәсен гел җилләтеп торырга да онытмасыннар иде. Газ җиһазлары урнашкан бүлмәдә йокларга ярамый. Аларны үзлегеңнән төзәтергә, сүтәргә, ялгарга маташу да кеше гомере өчен аяныч тәмамланырга мөмкин», – ди белгеч.

Гомуми практика табибы Фәния Ибраһимова сүзләренә караганда, сөрем газы белән агуланган кешенең башы әйләнә, күңеле болгана, коса, колагы шаулый башлый. Андый чакта кеше ярсырга яки, киресенчә, сүлпәнләнергә, йокыга талырга мөмкин. «Сөрем белән агуланган кеше колагы начар ишетү, күзе начар күрүдән дә зарланырга мөмкин. Ул йөрәк-кан тамырлары системасына да бәрә. Шуңа күрә кеше сөрем газы белән агуланудан бигрәк, йөрәге туктау яки инфаркттан үләргә мөмкин», – ди табиб.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

СӨРЕМ ГАЗЫ БЕЛӘН АГУЛАНГАН КЕШЕГӘ НИЧЕК БЕРЕНЧЕ ЯРДӘМ КҮРСӘТЕРГӘ?

- Агуланган кешене кичекмәстән саф һавага алып чыгыгыз. Әгәр аны саф һавага алып чыгу мөмкинлеге булмаса, форточканы, ишекне ачарга кирәк.
- «Ашыгыч ярдәм» чакырыгыз.
- Агуланган кешенең якаларын ычкындырып, кысып торучы киемнәрен салдырыгыз. Башына һәм күкрәгенә салкын сулы компресс яки бозлы шешә куярга, чигәләрен серкә яки нашатырь спирты белән уарга да онытмагыз. Агуланучыга кайнар чәй яки каһвә эчертергә, содалы су (1 литр суга 1 аш кашыгы сода) бирергә мөмкин.
- Әгәр аңын югалткан булса, 5 минут саен нашатырь спирты иснәтеп торырга кирәк. Әгәр сулыш алмаса, ясалма сулыш алдырасы һәм йөрәгенә массаж ясыйсы. Аңына килгәч, куе кайнар чәй эчертегез.

Сүзгә-сүз

Дмитрий ПАТРУШЕВ, Россия авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры:

Россиядә сезонлы кыр эшләре ахырына якынлаша диярлек. 2021 елда бөртеклеләрнең уңышы 123 млн тоннадан артып китәчәк, ә шуның 76 млн тоннасы – бодай. Бу безнең эчке һәм экспорт ихтыяҗларын тулысынча тәэмин итә. 23 млн тонна үсемлек мае культуралары, 40 млн тоннадан артык шикәр чөгендере, 7 млн тоннага якын яшелчә, 6,7 млн тонна бәрәңге алыначак. Бу күрсәткечләр узган елгыдан югарырак.

(Дәүләт Думасындагы «Хөкүмәт сәгате»ндә чыгышыннан)

РОССИЯДӘ – ИНТЕРНЕТКА ЫШАНЫЧ

Россиядә яшәүчеләрнең күпчелеге интернетка ышанмый һәм ялган мәгълүматлардан курка. «Диалог» оешмасы һәм интернет-технологияләр төбәк иҗтимагый үзәге (РОЦИТ) оештырган сораштыру нәтиҗәләре шуны дәлилли. Сораштыруда катнашучыларның 97 проценты ялган хәбәрләрнең нәрсә икәнен белә булып чыкты.

ХАЛЫК ФИКЕРЕНЧӘ, ЯЛГАН ХӘБӘРЛӘРНЕҢ ТӨП ЧЫГАНАКЛАРЫ

- 74% → онлайн матбугат чаралары
- 64% → традицион мәгълүмат чаралары һәм телевидение
- 38% → социаль челтәрләр

Бер очрак та теркәлмәгән

Быел Россиядә террорчылык гамәлләре булмыйча калган. Илкүләм террорчылыкка каршы комитет белдергәнчә, әзерләү этабында 65 җинаять туктатылып калган, 23 җинаятьче юк ителгән, 312се тоткарланган. Моннан тыш аларның 821 ярдәмчесе эшенә аяк чалынган. Террорчылык эшчәнлегенә катнашы булган 920дән артыграк кеше илгә кертелмәгән. Шулай ук халыкара террорчылык оешмаларының 62 яшерен бүлегенең эшчәнлеге туктатылган. Моннан тыш террорчылыкка катнашы булган кешеләрнең барлыгы 100 миллион сумнан артыграк акчасы белән счетлары ябылган, дип хәбәр итә ТАСС.

Мәсәлән, ФСБ хезмәткәрләре октябрь аенда Ставрополь краенда әзерләнелүче терактны булдырмыйча калган. Анда кулдан эшләнгән шартлаткыч ярдәмендә транспортны шартлату планлаштырылган булган.

Аренда хакы үсә

Зур шәһәрләрдә фатирны арендага алып тору бәясе бер ел эчендә (узган елның ноябреннән быелгы ноябрьгә кадәр) 31 процентка үскән. Ил буенча аренданың уртача бәясе аена 23 мең сумга җиткән. Быел гыйнвар аеннан бирле мондый торакка ихтыяҗ 24 процентка арткан.

Халкы миллионнан арткан шәһәрләрдә бер бүлмәле фатирда яшәп тору хакы бер ел эчендә 21 процентка үсеп, декабрь башына – 20,4 мең сумга, ике бүлмәледә – 30,3 мең сумга (үсеш – 23%), өч бүлмәледә 45,8 мең сумга (20%) җиткән. Гомумән, быел торакны арендалау бәясе рекордлы үсеш кичергән. Узган елда ноябрь аеннан башлап, аеруча Мәскәүдә (60,5%), Казан (44,3%) һәм Санкт-Петербургта (33,5%) бер бүлмәле фатирда яшәп тору бәяләре нык арткан.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ХАОС ҺӘМ КЕНТУККИ ФАҖИГАСЕ

Дөнья сәясәтендә аек акыл белән аңлау мөмкин булмаган вакыйгалар чылбыры дәвам итә. Европада газга һәм электр энергиясенә бәяләр тарихи рекордлар куя. Бәяләрнең бәйдән ычкынуы Украина тирәсендәге вазгыятькә бәйле. Көнбатышта Россия әнә-менә көнбатыш кардәшенә һөҗүм итәргә тора дип санныйлар һәм «малайны чүлмәкне ватканчы кыйнап кую» принцибын төп кагыйдә итеп алдылар. Саклагычларда газ бик аз булуга карамастан, көнбатыш илләре, аерым алганда Германия «Төньяк агым – 2» дип аталган торбадан газ куарга рөхсәт итмиләр. Атна башында Алманиянең тышкы эшләр министры Анналена Бербок торбаның Европа Союзы нормаларына туры килмәвен әйтте һәм: «Бу хәлдә хуплана алмый», – дип белдерде. Торбадан тыш та, Россиягә каршы кертелгән һәм кертелергә җыенган санкцияләрнең тулы бер коллекциясе бар. Кызыгы шунда: «Газпром» «Төньяк агым – 2»не бикләүдән оттырмый, ота гына. Бәяләр үсеше газ монополистының табышын чүпрә кебек үстерә. Дөрес, ул табыштан россиялеләр бик отмый кебек, чөнки акча шул ук көнбатыштагы офшорларда сеңеп кала. Хәлләрнең мондый кискенләшүеннән халыклар оттыра, билгеле. Ягулыкка мохтаҗ булган илләрдә генә түгел, газ һәм нефть өстендә утырган Норвегиядә дә электрга бәяләр рекорд артыннан рекорд куя. Безнең үзебездә дә бит инде мотор ягулыгы бәйдән ычкынырга торган эт кебек тота үзен. Икътисади кыенлыклар махсус оештырыла, дөньякүләм кара көч «идарә ителешле хаос» дигән планны тормышка ашыра. Болганчык суда, бердән, олигархлар күп акча эшли, икенчедән, ачыргаланган халыкны «яңа дөнья тәртибе»нә куып кертү җиңел булыр дип уйлыйлар. Миңа калса, конфликтлар якларның үзара килешүе белән оештырыла. Әмма хаос белән идарә итү торган саен кыенрак була бара. Дүшәмбе көнне протест Италия парламентына бәреп керде: вазгыятьтән риза булмаучылар кулларына плакат тотып чыктылар һәм бәрелеш оештырдылар.

Кешелек дөньясы үзара шулай болганган һәм чайкалган вакытта, табигый бәла-казалар белән дә сынала. 11 декабрьгә каршы төндә Американың Мэйфилд шәһәрендә торнадо шәмнәр җитештерүче заводны җир белән тигезләде. Тәүлек буе туктамый эшли торган заводта 8 кеше үлде, диделәр. Илдә дистәләгән торнадо котырынды ул көннәрдә. Миссисипи, Миссури, Арканзас, Иллинойс һәм Теннесси штатлары бөтерелеп исүче җил белән авыр сыналдылар. Кентукки штатында гына да кимендә 74 кеше һәлак булды. Фаҗига корбаннары саны артыр, мөгаен, чөнки йөздән артык кеше әлегә хәбәрсез югалган дип санала. Иң куәтле торнадоларның берсе 227 миль сузымындагы (365 километр) арада бик күп җимерекләр калдырып узды. Кентуккидан башка штатларда да үлүчеләр бар. Байден бу торнадоларны Кушма Штатлар тарихындагы иң көчлесе дип бәяләде.

Россиядә

БАНК СИСТЕМАСЫН ҖИМЕРЕРГӘ

Халыкара хәл, Россия белән турыдан-туры бәйле булганлыктан, ил эчендә киеренкелек китереп чыгармый кала алмый. Океан артыннан Россияне аның финанс системасын җимереп ташлау, банкларны түнтәрү, тышкы базарлар белән акча күчереп хезмәттәшлек итү мөкинлегеннән мәхрүм итү белән куркыталар. Сер түгел: Россия җитәкчелеге һәм олигархлар өчен дәһшәтле янау бу. Илнең төп акчалата байлыклары бит чит ил банкларында саклана. Менә шулар бикләнсә, җитди кыенлыклар көтә. Байден теле белән Мәскәүгә финанс санкцияләре кертәбез дип янау бу атна башында ил биржаларында сизелерлек тетрәү китереп чыгарды. Үзебезнең спекулянтлар да, күрәсең, сугыш булмас дип ышанып ук бетмиләр. Дүшәмбе сәүдәсе Мәскәү биржасында дәүләт банкларының акцияләреннән күпләп котылу өянәге китереп чыгарды. «Саклык банкы» акцияләре 5,63 процентка очсызландылар (бер акция бәясе 280,65 сумга кадәр түбәнәйде), ВТБ кәгазьләре 6,69 процент кыйммәтләрен югалттылар һәм бер данәсе 42,865 сумга калып, «төпкә утырдылар». Октябрь аенда алар иң югары бәягә ирешкән булганнар, менә шул биеклектән 25 процентка түбәнәйделәр. Югалтуларның күләме сумнарга күчергәч яхшырак күренә. Ике банк бергәләп ике триллион сумнан артык кыйммәтләрен югалтканнар. Бик күп акча бу. Бер яктан «Газпром» (шулай ук дәүләт компаниясе) санкцияләр нәтиҗәсендә кесәсенә табыш тутыра, икенче яктан дәүләт банклары акчадан мәхрүм кала. Отыш күпме дә, оттырыш күпме икәнен исәпләп тә бетереп булмый.

Америкада Байден командасы, Россия сугыш башласа, финанс блокадасы ясау турында документ әзерли. Закон проектын язучы демократ Роберт Менендес: «Россиянең банк секторы юк ителәчәк. Суверен әҗәтләр бикләнәчәк. Россия SWIFT түләүләр системасыннан колак кагачак. Сектор санкцияләре Россия икътисадын гарипләндерәчәк», – дип яный һәм кертеләчәк тыюларны «барлык санкцияләрнең анасы» дип атый.

Россия банклары Америкада һәм Европада хисап ачу мөмкинлегеннән мәхрүм ителергә ихтимал. «Саклык банкы» физик затларның депозитындагы 2 сумның берсен Америкада саклый икән. Янаулар тормышка ашырылса, депозитлар чүпкә әйләнергә мөмкин бит. 1991 елда «Саклык банкы»ндагы бөтен кертемнәр бикләнде һәм юкка чыкты. Бу хәл тагын кабатлана ала, димәк.

Әлегә көнбатыштан янаулар гына ишетелә. Андый янауларның күбесе тормышка ашырылмый килде моңарчы. Әмма янаулар фонында гына да триллионлаган сумнар юкка чыга икән, алар тормышка ашырылса, ниләр буласын чамалау кыен түгел. Көнбатыш инвесторлары (спекулянтлар) үткән атнада Россия хөкүмәтенең әҗәт кәгазьләрен (ОФЗ) күпләп саттылар. Байтак акча илне ташлап китте.

Янаулар фонында Россиянең үзәк банкы 17 декабрьдә төп ставканы яңадан күтәрергә, 7,5 проценттан 8,5кә җиткерергә җыена. Бу Россиянең әҗәт кәгазьләренең табышлылыгын күтәрәчәк. Чит ил инвесторлары хәвефкә карамыйча яңадан долларны ОФЗларга алыштырырлармы – анысын киләчәктә күрербез. Әлегә төп ставканың күтәрелүе инфляцияне авызлыкламады. Үзәк банк максатына ирешмәде, димәк.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

НЕФТЬ, ГАЗ ҺӘМ ТАТАРЛАР

РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ САНКТ-ПЕТЕРБУРГКА СӘФӘР КЫЛДЫ

Тау эшләре университетында Татарстанда Компетенцияләр үзәген булдыру турында килешү имзаланды. Президент Нева буендагы каланың губернаторы белән очрашты, милләттәшләребезнең хәлен белеште.

tatarstan.ru

Санкт-Петербугта Президент җитәкчелегендәге делегация иң элек Тау эшләре университетында булды. Биредә аларга уку йортының лабораториясен күрсәттеләр. Университет җитәкчелеге белән очрашуда исә уртак проектлар турында сөйләштеләр. «Уртак эш буенча планнар зур. Без 1943 елдан бирле нефть чыгару белән шөгыльләнәбез, шуңа күрә Тау эшләре университетында күргәннәребез кызыксындыра», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Тау эшләре университетында Татарстанда минераль чимал комплексы өлкәсендә төбәк Компетенцияләр үзәген булдыру турында килешү имзаланды. Әлеге үзәк Әлмәт дәүләт нефть институты базасында корылачак. Төп максаты – заманча кадрлар әзерләү, булган тәҗрибәне уртаклашу, яңа технологияләр булдыру. Моннан тыш, яклар уртак фәнни эшләр дә алып барырга ниятли. Сүз уңаеннан, мондый үзәкләр Бөекбритания, Алмания, Австрия, Финляндия, Кытай, Казахстан, Әрмәнстан һәм Белоруссиядә бар, Россиядә исә Ханты-Манси автоном округында, «ФосАгро» һәм «Сибур-холдинг» компанияләре базаларында эшли. Президент Рөстәм Миңнеханов фикеренчә, Татарстанда мондый үзәк кору Санкт-Петербург тау эшләре университетының тәҗрибәсеннән файдаланырга мөмкинлек бирәчәк. «Бу безгә бик кирәк», – диде ул.

Рөстәм Миңнеханов Санкт-Петербургта «Газпром» ГАҖ идарәсе рәисе урынбасары Виталий Маркелов белән республиканың газ тармагы нәтиҗәләре турында фикер алышты. Соңгы елларда Татарстанда табигый газ куллану сизелерлек артты. 2021 ел нәтиҗәләре буенча, ул якынча 18 млрд куб метр тәшкил итәргә тиеш. 2030 елга исә әлеге күрсәткеч 33 млрд куб метрга җитәр дип фаразлана. Төп сәбәбе Кама сәнәгать кластеры үсеше белән бәйле.

Моннан тыш, республикада ел саен 19 мең фатир һәм йортка газ кертелә. Хәзер аларның саны 1,5 миллионнан артып китә. Билгеле булганча, Россия Президенты Владимир Путин күрсәтмәсе буенча йортларны газга бушлай тоташтырып бетерү (догазификация) программасы эшли башлады. Татарстандагы 903 торак пункттагы 18 меңнән артык йортның хуҗасы әлеге программага өметләнә ала. Газ-мотор ягулыгы юнәлешендә эш алып барыла. Татарстанда табигый газны сыекландыру буенча Теләче һәм Биектау районнарында, шулай ук «Алабуга» махсус икътисади зонасы территориясендә өч комплекс төзелә.

Татарстан Президенты Санкт-Петербургта яшәүче милләттәшләребезнең дә хәлен белеште. Рәсми саннарга караганда, Нева буендагы тарихи калада 30857 татар яши, Ленинград өлкәсендә аларның саны – 8693. Шәһәрдә һәм өлкәдә берничә милли оешма эшли.

Санкт-Петербург губернаторы Александр Беглов белән очрашуда Татарстан Президенты татар иҗтимагый оешмалары эшчәнлегенә игътибары һәм күрсәткән ярдәме өчен рәхмәт белдерде. Александр Беглов исә төбәкләр арасындагы хезмәттәшлекнең әһәмиятле булуын әйтте. Татарстанның Санкт-Петербургтагы тулы вәкаләтле вәкиллеге моннан 25 ел элек барлыкка килгән.

Очрашуда КамАЗ белән хезмәттәшлек турында сүз булды. Чаллыдан Санкт-Петербургка автобуслар җибәрәләр. Ике арадагы товар әйләнешенең күләме соңгы елларда 31 млрд сум булган. Татарстан Санкт-Петербургка йөк машиналары һәм автобуслардан тыш, шиннар, бензин һәм дизель ягулыгы, азык-төлек, суыткычлар җибәрә. Зур предприятиеләр арасында хезмәттәшлек корылган. Губернатор белән очрашуда элемтәләрне тагын да ныгыту турында сөйләштеләр.

Кыш бабайдан алданрак



«Татар-информ»

«Бердәм Россия»нең Татарстандагы бүлеге «Теләкләр чыршысы» хәйрия акциясенә кушылды. Партия вәкилләре «Елка желаний» сайтында Татарстанда яшәүче балалар Яңа ел алдыннан язып калдырган теләк-хатларны сайлап алды.

Люба Калашникова Казанда яши. Начар ишетүче кыз Кыш бабайдан планшет сораган. Бүләкне аңа «Бердәм Россия» партиясенең Татарстандагы төбәк бүлеге Секретаре, Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин тапшырды.

10 яшьлек Лиана Ибраһимова ДЦП белән авырый. Ул да, Люба кебек үк, планшетлы булу турында хыялланган. Аның теләген партиянең төбәк башкарма комитеты җитәкчесе Марат Сәмигуллин үтәде. Лиананың әти-әниләре әйтүенчә, планшет кызчыкка хәрефләр танырга, тапкырлау таблицасын өйрәнергә ярдәм итәчәк.

Тагын бер планшет Айзилә Габидуллинага эләкте. Бүләкне аңа Төбәк хезмәттәшлеге һәм үсешенә ярдәм итү буенча Татарстан иҗтимагый фонды президенты Геннадий Глушков тапшырды. «Бердәм Россия» партиясе Рәисенең төбәк иҗтимагый кабул итү бүлеге җитәкчесе Камил Садриев Полина Варинага этюдник бүләк итте. Партия тарафдарлары советыннан бүләк – «Яндекс»-станция Чаллыда яшәүче 11 яшьлек Камилә Шәмсетдиновага юлланачак.

«Татарстанда Яңа ел алдыннан, партиягә мөрәҗәгать итеп, игътибар-ярдәм сораучыларны котлау изге традициягә әйләнде. «Бердәм Россия»нең Татарстандагы бүлеге барлык депутатларны теләкләр үтәүгә җәлеп итә. Бу эшне без чын күңелдән, зур канәгатьлек хисе белән башкарабыз һәм якынлашып килүче 2022 елда һәрбарчабызга саулык-сәламәтлек, иминлек, бәхет телибез», – диде Фәрит Мөхәммәтшин. Аның әйтүенчә, акциядә катнашучылар саны елдан-ел арта.

Хәерле юл!

Туристлык юлламасы алганда тотылган акчаның бер өлешен кире кайтару (кешбэк) программасы киләсе елда да гамәлдә булачак. Ул 18 гыйнварда башланып, 12 апрельгә кадәр дәвам итәчәк һәм моның өчен 5 миллиард сум акча сарыф итәргә ниятлиләр.

Шартлары элеккечә: туристның банк картасына сәяхәт итү яки яшәү бәясенең 20 проценты (күп дигәндә – 20 мең сум) кире кайтарыла. Әмма аның өчен «Мир» картасы белән түләргә кирәк. Кешбэк белән 18 гыйнвардан 30 апрельгә кадәр илнең теләсә кайсы төбәгенә сәяхәт итәргә мөмкин. Программага кимендә ике төн кунакханәдә яшәү һәм сәфәр кылу кертелгән.

Узган елда Ростуризм башлап җибәргән кешбэк программасы – туристлар өчен дә, бизнес өчен дә бик зур ярдәм булды. Агымдагы ел башыннан бирле программадан 1,7 миллион чамасы кеше файдаланган. Алар барлыгы чама белән 34 миллиард сумлык сәяхәт туры һәм кунакханәдә урыннар сатып алган. Туристларның банк карталарына кешбэк рәвешендә 6,7 миллиард сум кире кайтарылган.

Кунакханә-туристлык тармагында эшләүчеләрнең күпчелеге фикеренчә, программа бик зур социаль-икътисади нәтиҗә күрсәткән. Белгечләр исәпләп чыгарганча, кешбэктан файдаланган туристларның кимендә 50 проценты, фәкать программага кызыгып, ил буенча сәфәр чыгарга карар иткән. Программа шулай ук балалы гаиләләрнең сәяхәт итү мөмкинлекләрен арттырган. Моннан тыш Ерак Көнчыгыш, Себер, Төньяк һәм Арктика юнәлешләрендәге сәфәрләргә ихтыяҗ нык үскән.

ИШЕГАЛДЫМ МИНЕМ...

Яшәргә өйрәнәбез

Күпфатирлы йортларда яшәүчеләрнең күбесе «Безнең ишегалды» программасы кысасында йорт тирәсендәге юлларны яхшыртуны сорыйлар икән. Сукмак булмасын – тротуар кирәк, чирәм үсмәсен – асфальт җәегез. Халыкның тәкъдим-үтенечләрен күздә тотып, киләсе елда ишегалларында ниләр булачагын хәл итәләр дә инде.

dvor.tatar

2021 елда Татарстанда «Безнең ишегалды» программасы буенча 1078 ишегалды төзекләндерелгән. Моңа 8 млрд сум акча сарыф ителгән. Киләсе елда күпме ишегалдында эш барачагы әлегә билгеле түгел, быелга караганда күбрәк булыр дип планлаштырыла. Район хакимиятләре тәкъдим иткән исемлек әлегә расланмаган. Бу хакта Хөкүмәт йортында узган брифингта сөйләделәр.

– «Безнең ишегалды» программасы эшли башлаганнан бирле, 6923 ишегалды тәртипкә китерелде. Республикада 2 миллионга якын кеше төзекләндерелгән ишегалларында яши, – ди Татарстанның төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Марат Айзатуллин. – Халык үтенече буенча, без юлларга өстенлек бирәбез. Аеруча тротуарларга игътибар зур. Ник дигәндә, бу юллар халыкны үзенә кирәкле социаль әһәмияткә ия урыннарга алып чыга. Ут куюны сораучылар да күп. Шуны истә тотып, 2021 елда 6 меңнән артык яктырту баганасы куйдык.

«Татарстан шәһәрләре үсеше институты» фонды директоры урынбасары, «Безнең ишегалды» программасы координаторы Венера Камалова әйтүенчә, һәркем үзе яшәгән урынның нинди буласын сайлый ала. Сайлау гына түгел, башкарачак эшләр белән танышып, аннары аларның үтәлешен контрольдә тота.

– 2022 елда төзекләндереләчәк 200 ишегалдын халык ярдәме белән сайладык. Моның өчен dvor.tatar сайтына керергә кирәк. Исемлекне документлар бүлегендә табып була. Республикада яшәүче кешеләр үз ишегалды әлеге программага кертелсен өчен тавыш бирде, – ди Венера Камалова.

Әлеге сайтта халыкның фикерен дә белешкәннәр. Ишегалдына бәйле сораштыру үткәргәннәр. Баксаң, катнашучыларның 92 проценты күпмедер вакытын ишегалдында уздыра икән. Кешеләрнең 67 проценты урамда җәяү йөрергә яратканын әйткән. 16 проценты – бала белән йөрергә урын кирәген, 24 проценты 3 яшькәчә балаларга уңайлы зоналар юклыгын җиткергән.

– Яшь әниләрне аңлап була. Дөрестән дә, ишегалдындагы җиһазлар 3 яшьтән зуррак балалар өчен куела. Шуңа да киләчәктә бәләкәчләр өчен комлык булдыруны күз алдында тотабыз. Сораштырулардан күренгәнчә, халыкның 31 проценты – урамнарның караңгы булуыннан, 27 проценты ишегалдында машиналар күплектән зарлана. Әлеге үтенеч бик күпләрне борчый. Кайчак каршылыклар булса да, уртак фикергә килеп, без аны да хәл итәбез. Кеше машинасын тиешле урынга куярга тиеш. Яшеллек өстендә, тротуарда калдыру дөрес түгел. Без һәр зарны ишетәбез. Бер генә мөрәҗәгать тә җавапсыз калмый, – ди Венера Камалова.

Халык үз фикерләрен сайт аша гына түгел, 8 (800) 275-20-20 номерына шалтыратып, шулай ук социаль челтәрләрдә дә калдыра ала. Узган ел «кайнар элемтә»гә 16 мең мөрәҗәгать килсә, быел 12 мең кеше шалтыраткан. Социаль челтәрләр аша көненә 40–44 хәбәр килә икән. Төзекләндереләсе ишегаллары исемлеге дә халык шикаятьләреннән чыгып төзелә. Әмма гел зар гына түгел, рәхмәт сүзләрен дә еш әйтәләр. Аеруча Зәй, Әлмәт, Азнакай, Мөслим районнарыннан күп икән андый җылы хәбәрләр. Венера Камалова тагын шунысын да әйтеп үтте: ишегаллары төзекләндерелгәч, шул тирәдәге фатирларның бәяләре дә арткан икән.

«БЕЗНЕҢ ИШЕГАЛДЫ» ПРОГРАММАСЫ КЫСАСЫНДА БАШКАРЫЛА ТОРГАН ЭШЛӘР:
- юл, тротуарлар төзекләндерелә;
- эскәмияләр, чүп савытлары куела;
- ут яктырткыч баганалар төзекләндерелә яки яңалары куела;
- балаларга уен һәм спорт җиһазлары куела;
- каты көнкүреш калдыклары өчен мәйданчыклар булдырыла яки яңартыла.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

АЯЗ ШӘФИГУЛЛИН:

«ЮТАЗЫ – СӘНӘГАТЬ ӨЛКӘСЕНДӘ УҢЫШЛЫ РАЙОН»

«Кояш бездә иртә чыга». Республиканың Башкортстан белән чиктәш Ютазы районы халкыннан бу сүзләрне еш ишетергә туры килә. Быел ул 30 еллыгын билгеләп узды. Район башлыгы Аяз ШӘФИГУЛЛИН белән аның үткәне һәм бүгенгесе турында сөйләштек.

jutaza.tatarstan.ru

– Ютазы районында 20500 кеше яши. Шуның 73,7 проценты – татарлар, 24 проценты – руслар һәм башка милләт вәкилләре, – дип сүзен башлады ул. – Урыссуда 10500 кеше көн күрә. Шуның 46 проценты – руслар. Быелгы сан алу районда чуашлар саны артуын күрсәтте. 1990 нчы еллар башында Урыссудагы немецлар 7 процентка кадәр җиткән иде. Шул еллардан соң аларның күпчелеге Германиягә күченеп китте. Республикадагы иң озын күпер дә – Ютазы районында. Озынлыгы зур булмаса да, аны ике сәгать чыгасы, чөнки күршедәге Башкортстанда вакыт аермасы – 2 сәгать. Башкортстан белән чиктәш булгач, аралашып яшибез. Октябрьск шәһәренә барып эшләүчеләр күп. Аларныкылар бездә эш урыны таба. Пандемия башлангач та шәһәр мэры белән кулга-кул тотынышып, киңәшләшеп эшләдек. Бездә табибларга кытлык юк. Аннан соң, Октябрьск шәһәре белән чагыштырганда, бездә җирләр арзанрак. Монда торып, шәһәргә эшкә баручылар күп.

:: Аяз Әдипович, Ютазының үзенчәлеге – бренды нәрсә?

– Күпләр, Ютазы – чиста авыл хуҗалыгы районы, дип уйлый. Ләкин бу алай түгел. Районның эчке территориаль продуктының 56 проценты сәнәгать белән бәйле. Бездә «Татнефть» тә, «Башнефть» тә бар, ләкин беркайчан да НГДУ булмады. Аның каравы бездә бүген бөтен предприятиеләр дә эшли. Безнең район эчендә ике тимер юл станциясе генә бар. Оборона заводында 850 кеше эшли. Урыссуда «Руда булмаган материаллар предприятиесе» гравий, ком чыгара. Элеваторыбыз бар. Төзелеш материаллары әзерли торган комбинат эшләп тора. Шуңа күрә район халкы тырыш.

Авыл хуҗалыгына килгәндә, безнең хуҗалыкларның берсенә дә инвестор кермәгән. Һәм эшкәртелмәгән бер генә сутый да җир юк. Монда барысы да – үзебезнең фермерлар, егетләр. Бүген дә: «Җир бирегез әле», – дип керәләр. Фермерлар эшләүнең зур уңышы – авыллар исән калды. Әгәр авыл хуҗалыгы предприятиесе бар икән, димәк, анда халкы мал тота, юллары кардан ачылган, сулары каралган. Иң зур авыл хуҗалыгы оешмасының җирләре 7 мең гектар булса, иң кечкенәсенеке – 50 гектар. Бу тармакта уртача хезмәт хакы – 30 мең сум. Район буенча 35–36 мең сум тирәсе чыга. Терлекчелек, игенчелек белән беррәттән җиләк үстерүчеләр, яшелчәчелек, кошчылык белән шөгыльләнүчеләр бар.

:: Танылган композитор Софья Гобәйдуллинаның да тамырлары Ютазыга бәйләнгән.

– Һичшиксез, без гыйлемле, укымышлы кешеләребез белән дә горурлана алабыз. Кәрәкәшле авылында гына да алты академигыбыз бар. Танылган композитор Софья Гобәйдуллинаның һәм аның туганнарының исеме шулай ук Ютазы районы белән тыгыз бәйләнгән. Бәйрәкә авылында Софья Гобәйдуллинаның бабасы Мәсгут Габделгали улы Гобәйдуллин мәчет имамы вазыйфасын башкарган. Заманында авылда 7 мәчет булган.

:: Район өчен 30 ел күп тә түгел кебек. Шулай да, шушы еллар эчендә Ютазының йөзе ни дәрәҗәдә үзгәрде?

– Мин чыгышым белән шушы районнан. Укырга биш елга гына китеп алдым да, тормышымның калган еллары биредә узды. Район күзгә карап матурланды, камилләште. Бүген сәнәгать мәйданында 17 резидент эшли. Юллар буенча да проблема юк, чөнки районыбызның унитар предприятиесе бар. Аның үзенең асфальт заводы бар. Быел 43 ишегалдын төзекләндердек. Шуның 20се авыл җирлекләрендә эшләнде. Моннан тыш, грантлар отып, авылларда парклар кора башладык. Авыл халкына шәһәрдә яшәүчеләр белән тигез дәрәҗәдә мөмкинлекләр тудырылырга тиеш, дип саныйм. Ютазы ул – Урыссу бистәсе генә түгел, ә 38 авыл да. Ике ел эчендә Акбаш, Ютазы, Подгорный, Иске Урыссу, Кече Урыссу җирлекләрендә парклар ясадык. Авыл хуҗалыгы тармагында эшләүчеләргә арендалы торак программасында катнашу мөмкинлеген бирдек. Биш ел эшләгәч, ул йортны сатып ала алалар. Шуңа күрә безнең төп бурыч – кечкенә авылларны бетермәү. Бүген газ кермәгән бер генә авыл да юк. Авылларда, җирлекләрдә халыкны ничек калдырырга була икән, дип уйлый идем. Башта бу мәсьәләнең чишелешен йортлар төзүдә күрдем. Юк, алай булмады. Безнең күпчелек ир-ат Себергә барып эшли. Мондагы хезмәт хаклары да андагы белән тигезләште диярлек. Ләкин һаман да читтә эшләүләрен дәвам итәләр. «Ник алай?» – дип сорагач: «Бер ай эшлибез дә, тынычлап, бер ай ял итәбез. Көн саен иртәдән кичкә кадәр эшләүдән киттек инде без», – диләр. Шуңа күрә иң авыр мәсьәләләрнең берсе – кадрлар җитмәү.

:: Быел шактый сынаулы ел булды. Яңа елга нинди сабак алып керәсез?

– Хәзер авыручылар кимеде инде. Вакцина ясатучылар да күп. Шулай да, 60 яшьтән өлкәнрәкләр белән эшләү авыр әле. Кызганыч, күпләр «ул миңа кагылмас» дип уйлый. Сабак алу дисәк, беренчедән, прививка кирәклегенә төшендек. Авырудан качып котылып булмаячагын аңладык. Икенчедән, оптимизациянең тискәре нәтиҗәләрен күрдек. Үз вакытында без бөтен йогышлы авыруларны дәвалый торган хастаханәләрне ябып, берләштереп бетердек. Ә менә шушы авыру килеп чыккач, аның ялгыш адым булуын аңладык. Авыручылар белән башта Әлмәт, аннан Лениногорск, Бөгелмә хастаханәләре тулды. Нәтиҗәдә үзебездә кабаттан йогышлы авырулар бүлеге ачып эшли башладык. Өченчедән, халыкта дисциплинаның булмавын аңладык. Авырулар санын киметер өчен бирелгән ялларда халык, киресенчә, чит илгә чыгып, чир ташыды. Киләчәктә әлеге сабаклар уңай нәтиҗәләргә ирешергә этәргеч бирер дип өметләник.

Зөһрә САДЫЙКОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасының мәдәни-рухи мирасын саклауга һәм баетуга зур өлеш кертүе өчен язучы, «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» җәмәгать оешмасы (Иҗат берлеге) әгъзасы **Галиев** Марсель Баян улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Вокалчы артист (солист), шәхси эшкуар **Бәдретдинова** Илсөя Ядкарь кызына, «Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең Татарстан Республикасы Филармония джаз-оркестры сәнгать җитәкчесе, баш дирижеры **Васильев** Сергей Леонидовичка, вокалчы артист (солист) **Мулин** Максим Вадимовичка **«Татарстан Республикасының атказанган артисты»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең уку-укыту бүлеге башлыгы **Булатова** Резедә Рәдиф кызына, «Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең оркестр факультеты деканы **Шмаевский** Олег Владимировичка **«Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

ХАБАРОВСК КРАЕНДА ЯШӘҮЧЕ КУЗНЕЦОВЛАР:

«Татарча сөйләшмәгән өчен штраф салабыз»

Алар рус мәктәпләрендә укыса да, балаларын татарчага өйрәтергә тырыша. Бу әле татар теле яңгырап торган җирдә түгел, аны ишетү тансык булган чит төбәктә. Хабаровск краенда яшәүче Кузнецовлар гаиләсендә туган телне өйрәтүнең үз тәртибе. Гаилә башлыгы баштарак һәр рус сүзе өчен штраф керткән. Кагыйдәне кем үтәми – шуңа физик күнегүләр ясарга туры килгән. Биш балаларын да өйдә укыталар. Рәүфия белән Хәмзә гаиләсендә татар җанлы, туган телгә, җыр-моңга битараф булмаган балалар үсә.

«Без сакламасак, кем саклар?»

Күптән түгел Татар дәүләт курчак театры артистлары Хабаровск краена «Су анасы» спектаклен куярга килгән. Гаиләләре белән тамаша карарга барган Кузнецовларның хисләре эченә сыймый. «Бездә урамнарда, кибетләрдә татарча сөйләшмиләр. Белсәгез иде татар телен ишетүнең җанга нинди рәхәтлек биргәнен! Бу сусауны сүзләр белән гел аңлатып булмый», – ди Рәүфия.

Киров өлкәсендәге Кильмез авылында туып-үскән Рәүфия рус мәктәбендә укыган. Әгәр гаиләдә әти-әниләре татарча сөйләшмәсә, ул да туган телен белмәс иде. Ире Хәмзә белән шул ук хәл. Ләкин, без русча укыдык, шуңа күрә балалар белмәсә дә, гаеп түгел, дип туган телгә кул селтәмәгәннәр. Рус мохитендә үскән Хәмзә татарча сөйләшергә тырыша, ялгышрак әйткән сүзләрен Рәүфиясе дөресләп җибәрә. Өйләрендә «мама», «папа»лар да, «аника», «атика» ише сүзләр дә ишетелми. Бар да үзебезчә. Балалар бишек җырларын тыңлап үсә.

Рәүфия белән Хәмзәнең беренче очрашулары да көтелмәгәнчә була. Егет Хабаровскидан Нократ Аланы мәдрәсәсенә укырга килгән. Укып бетергәч, гаилә корыр өчен тәртипле татар кызы эзли башлый ул. Авыл мулласы Васил абый Рәүфия турында әйтә.

– Ураза вакыты. Коръән ашы үткәрергә әзерләнеп йөргән чак иде. Хәмзә белән танышып, берничә көн аралаштык та Хабаровскига киттек. Мәктәпне тәмамлап, һөнәр дә алырга өлгермәгән идем. Читтә гомер итүемә – 15 ел. Башта Чегдомын бистәсендә яшәдек, аннан Хабаровскига күчендек. Беркайда да укырга, эшләргә туры килмәде. Алты балабыз бар. Хәмзә дини оешмада эшли, – дип сөйли Рәүфия читкә китүе турында. – Читтә яшәсәк тә, булдыра алганча, балаларга туган телне өйрәтергә тырышабыз. Без сакламасак, татар телен кем саклар? Сөйләшмәсәң, югала бит ул, балалар да руслаша башлаячак. Татарча җырлар җырлыйбыз, әкиятләр укыйбыз, аларны бергәләп тәрҗемә итәбез. Өебездә китапханә бар. Андагы татар китапларының күбесен үзебез сатып алдык. Арада Бөтендөнья татар конгрессының җирле бүлеге җибәргәннәре дә бар. Кечкенәдән өйрәтмәсәң, балалар телне белмәячәк. Туган телне әти-әни өйрәтергә тиеш. Балаларыбыз үзләрен татар диләр.

Әдәпле балалар

Кузнецовлар, балалар телне, динне онытмасын, әхлаклы булсын дип, ул-кызларын мөселман онлайн мәктәбенә биргән. Олы кызлары Альбина мәктәпкә йөргән, әмма аллергия белән авыргач, өйдә укытуны кулайрак күргәннәр. Ә калган биш баланың бакчага, мәктәпкә бөтенләй барганы юк икән. Анда имтихан тапшырыр өчен генә баралар.

– Балалар мәктәпкә барасы килә дип әйтми. Ни өчен дигәндә, имтихан бирергә баргач та, сыйныфтагы хәлләрне, бер-берсе арасында этеш-төртешләрне күреп торалар. Сыйныфташларына карап аптырап утыралар. Мәктәптә тәрбия дә, яшьләр дә башка. Хәзер барысы үзгәрде, шуңа күрә өйдә тынычрак. Танышлар арасында да өйдә укытучылар шактый, – ди Рәүфия ханым. – Дин юлында булгач, намаз да укырга кирәк. Кызлар яулык бәйли. Мәктәптә рус балалары гына укый. Шуңа күрә дин тотар өчен мөмкинлек юк. Программада нәрсә бар, шуны өйрәнәләр. Өйдә белем алу һич кенә дә белем сыйфатына комачауламый. Мин укытучы булмагач, өйрәтә алмыйм анысы. Бары дәрескә керүләрен, өй эшләрен күзәтәм. Алар барысы да – мөстәкыйль. Таныш-белешләр, балаларыгыз бик тәртипле, дип соклана. Алар өйдә генә утырмый. Буш вакытта кемдер китап укый, бәйли, рәсем ясый.

Парлап уку

Кузнецовларның иртәсе намаздан башлана. Шуннан соң сәгать 11гә кадәр рәхәтләнеп йоклыйлар. Мәскәү онлайн мәктәбендә укыгач, аерма – 7 сәгать. Беренчедән, йокылары туйса, икенчедән, каядыр бару өчен гел укытучыдан сорарга кирәкми. Бу яктан иркле. Вакытында ашыйлар, ял итәләр. Саф һава сулыйлар. Уңай яклары күп.

Балаларны онлайн мәктәпкә парлап бирергә тырышалар. Сәмирә белән Мәрьям – 2, Җәмилә – 5, Мәдинә белән Әмир 7 нче сыйныфта укый. Репетиторга йөрү дигән нәрсә юк. Аңламаган әйберләрен интернеттан видео дәресләрдән дә карыйлар. Кечкенәләре көнгә – 2, 7 нче сыйныфтагылар 4–5 дәрес укый. Кемдер – планшет, телефон, кемдер компьютер ярдәмендә белем ала. Дәреслекләр күбрәк электрон форматта, әмма гади мәктәптән дә китаплар бирәләр.

Уку өчен дүрт балага айга 10 мең сум китә. Елга 90 мең сум дигән сүз. Бер гаиләдән күбрәк укыгач, ташламалар да ясыйлар икән. Кузнецовлар бәяне кыйммәт дип санамый. Гади мәктәптә чыгым әле күбрәк тә булыр иде, тәрбияне исә, гомумән, акча белән бәяләп булмый, диләр.

Сәрия МИФТАХОВА

ҖИРСҮ

Чечня көндәлеге

< Ахыры. Башы 8 декабрь санында

Грозныйда яши башлауга миңа иң күп бирелгән сорау мәктәп белән балалар бакчасы турында булгандыр. Хәзер балалар ничек йөри инде, анда бөтенесе мөселманча киенгән бит инде, анысы ярамый, монысы ярамый… Бу сорауны, дөресен әйткәндә, үзем дә аңламадым. Без дә мөселманнар ич! Шәһәрне яңгыратып көненә биш тапкыр азан яңгыравы, яулыклы апалар-әбиләр, кыска итәкләр, гаурәт җирләрен күрсәтеп йөрүчеләр булмауга зерә тиз ияләнәсең икән ул. Ә мәктәптә…

Башта түләүле мәктәп дип маташкан идек. Аннан инде дәүләт гимназиясен сайладык. Һәм мин аннан тулаем канәгать. Киенү буенча – итәк тездән түбән, блузка өстеннән жилет киелергә (эчке кием күренмәсен, беленмәсен өчен), башта мәктәп үзе үк бирә торган артка каратып бәйләнүче яулык булырга тиеш. Форма – катгый. Мәктәп киемсалымын тегүче махсус җирле фабрика бар: сыйфаты әйбәт, бәяләр тешләми. Анысы да монысы – тукыма безнең чорның мәктәп формасына охшаш, составында киндер бар кебек – ул шуның кадәр тыгызсыйфатлы, атна саен юып-үтүкләүләргә бирешә торганнардан түгел, кичә генә алган шикелле. Итәк – 1300, жилеты 1150 сум дип хәтерлим. Ел буена блузкаларны санамаганда, шул бер пар кием җитә дә. Казанда мәктәп кушкан җирдән ким дигәндә икешәр пар кием ала, ул ел ахырына биш буын рәттән киеп туздырган, чыкмаган җаны гына калган чүпрәккә әйләнә иде…

Хуш. Грозный. Мәктәпкә урнашуга монда укытыла торган туган тел – чечен теле мәсьәләсен хәл итәргә туры килде. Башта, батыраеп китеп, өйрәнербез, дигән идем директорга. Бераздан аның мөмкин түгеллегенә төшендек. Тел бик катлаулы (вайнахлар теле): «де дик дойл» (хәерле көн), «дел риз хиийл» (рәхмәтнең кыска варианты), «дела реза хуьлда» (Аллаһ риза булсын, рәхмәт яусын) кебек кыска сүзләрдән кала әле дә әллә нәрсәгә өйрәнә алмадык. Шуңа да чечен теле дәресен калдырмаска, әмма аттестациясез укырга дип килештек.

Ә мәктәптә чечен теле һәм әдәбияты атнасына 5 тапкыр (уку да биш көнлек) укытыла. Рус теле күбрәк кирәк, чечен теле белән БДИны ерып чыгып булмый дигән сораулар монда бирелми, чөнки монда урамда да ялгышып башка телдә сөйләшүне очратам димә. Нииндидер бәйрәмнәр, урам чаралары вакытында да бөтен бәйрәм-очрашулар бары тик чечен телендә алып барыла. Урамда рус телендә сөйләшеп барган ике егетне аксакал бабай туктатып тәнкыйтьләвен ишеткәнем булды. Җирле каналлар, социаль челтәрләрдә дә бөтен җитәкчеләр бары тик чечен телендә генә сөйләшә. Үзәк мәйданга җирле һөнәрчеләрнең бәйрәменә җыелдык шулай. Иң соңыннан нииндидер лотерея уйнаттылармы, әллә җиңүче алдан билгеле идеме – республика башлыгы үзе бүләкләр тапшырып котлады. Ник бер рус сүзе кыстырсын – чат чечен телендә сөйләде, аннан кемгәдер машина ачкычы тапшырды, мәйдан гүләде, кул чапты, без бер кәлимә сүз дә аңламадык… Туган телдә генә сөйләшкән чеченнәр безнең балаларга да нииндидер этәргеч булды – олы кызым хәзер бөтенләй рус сүзләре кыстырмыйча гына татарча сөйләшә башлады. Ана телеңне хөрмәт итү үзең татарча сөйләшүдән башлана шул, кем әйтмешли.

Мәктәптә Мәрьямне ничек кабул иттеләр, дигәннән. Бик җылы кабул иттеләр. (Алар безне татарцы диештерә. Безнең дә чеченцы урынына чечены дияргә тел кычыткан шикелле.) Бала өчен иң шакаткычы – сыйныфының бердәмлеге булгандыр. Беркайчан бер-берсен сатмыйлар. Балалык шуклыгы белән берәр нәрсә ваталармы, берберләреннән күчерәләрме, җавап бер: «Күрмәдем, белмәдем». Такта каршына чыгып, укырга онытып килгән егетләргә булышу өчен тулаем бер «Операция Ы» оештырыла. Беренче партадагы кешенең китабы тактага каратып борылып куела, арткарак киткән укытучыны арттагы партадагылар «тоткарлый», шул арада алдагыраклар пышылдый-пышылдый теге егеткә җавап тотарга булыша. Малайлар эткәләшеп-төрткәләшеп пластмасс ишекне сафтан чыгаргач, берәм-берәм җавап та алып карадылар: сыйныфлары белән су йоткан кебек басып торганнар.

Уку буенча бөтен нәрсә Казандагы лицееbыздагыча. Шул ук китаплар, шул ук программа. Мәҗбүри ашау картасы алу, мәҗбүри ашау кебек тәртип кенә юк – алары башлангыч сыйныфлар өчен генә. Урта һәм югары сыйныфлар үз теләге буенча туклана. Ашханәдәге бәяләрне дә языймдыр инде: камыр эчендәге сосиска 10 сум (телеңне йоттарлык тәмле, кайнар), мантый – 15, шешәле чиста су – 15, калай банкалы чәй – 35, чәй – 10, хәләл бургер – 50 сум. (Хәләл дип һәр җиргә өстәп тә тормасам буладыр, республикада дуңгыз ите шәһәр читендәге кибеттә генә сатыла.)

Мәктәптә акча җыю мәсьәләсен республика башлыгы контрольдә тота – сукыр бер тиен дә җыймыйбыз. Ата-аналар үзара килешеп, принтер өчен кәгазь, сыйныфтагы су краны янына сабын, чүп пакеты, рулонлы кәгазь җибәрештерәбез. Шуның белән шул.

Мәктәптә тәнәфес – 5 минут. Ашау өчен каралганы гына 10 минут дип беләм. Балалар көндезге икенче яртыда өйләренә таралыша.

Балалар бакчасы дигәндә, монда тотынып утырырга кирәктер. Мондагы шикелле хөррият, белмим, тагын кайда да булса бармы икән?

Башта минусыннан башлыйммы? Минусы бар һәм бер – балалар саны күп. Бер төркемдә кырыклап бала (аларның гадәттә яртысы йөри инде). Бу гаиләләрдәге балалар саны белән аңлатыладыр. Монда гадәттә гаиләдә иң ким бала саны – 3. Гадәттә 4–6. Балалар бакчасына эләгер өчен сират күпере узасы юк. Балалар бакчалары күп. Шәһәрдә 180гә якын дәүләтнеке саналган балалар бакчасы бар, моннан тыш коммерцияле бакчалар бик күп. Ә Грозныйда 324 меңнән артык кеше яши дип исәпләнә. Документларыңны «Минем документлар» дип аталган оешмага илтеп тапшыруга сине бер ай эчендә бакчалы итәләр. Махсус нәкъ менә шушысы кирәк дигәндә генә көтәргә туры килергә мөмкин.

Бакча өчен түләү. Игътибар! Әгәр гаиләдә бер бала икән – бакча өчен 2 мең сум акча түлисең. Ике бала икән – 1500 сум, өченче һәм аннан соңгы балалар өчен – 1000 сум. Бу өлкән балаларыңа ничә яшь, кайда укуларына карамастан. Һәм әлеге сумманың 50 проценты квартал саен картаңа яки банк счетыңа әйләнеп кайта тора. Әниләргә ярдәм! Бернинди гаилә кереме, кемнең күпме акча алып эшләве турында НДФЛ кәгазьләре дә, ул кәгазьләрне ярты елга бер яңартып тору да кирәкми. Әлеге хакка тулаем ашау кергән. Безнең бакчада, мисал өчен, моннан тыш инглиз һәм гарәп телләре укытыла. Әминә ялт иттереп догалар өйрәнә. Аларны махсус белемле гарәп теле укытучысы килеп укыта. Әйтелеш без өйдә өйрәткән догалар кебек транскрипция буенча түгел инде. Баланы тыңлап, «Кулһув Аллаһу»ларны дөресләргә өйрәндек. Моның өчен бер тиен дә түлисе юк – болар барысы да без түли торган 1500 сумга кергән! Бакчага Чечен дәүләт «Вайнах» бию ансамбленнән биюче егет килеп, балаларга бию дәресләре бирә. Әлеге түгәрәкнең бәясе – 1500 сум. Казан бакчаларыннан аермалык – балаларга мендәр-юрган тышлыгын үзең аласың, һәм атна саен үзең юып-үтүкләп алып киләсең. Бу аллергияле балалар арту белән аңлатыла. Шуңа күрә һәр ата-ана моны баласына килешкән ысул белән юып алып килсен өчен эшләнгән.

Театр-концертларга балалар белән йөрү дә хөррият. Былтыр Яңа ел тамашасына бардык, билет хакы бер балага 250 сум иде. Өч һәм аннан да күбрәк балалылар өчен гадәттә бөтен нәрсә – 100 сум. Һәм андый спектакль-чаралар вакытында тәм-томнар, өстәл хакларын арттыру юк – чәй гадәттә бөтенләй бушка булырга мөмкин, калган тәм-томнарга да юк бәя.

Түләүле балалар бакчаларының төре егермедән артып китә (күпләренең филиаллары да бар), хаклары 5 меңнән башлап 25–30 меңгә кадәр. Кайбер бакчалар хәтта балаларны өйдән килеп алып, кичен кайтарып та куя: аның өчен бакча хакына тагын мең ярым сум өстәп түлисе генә. Бу – махсус кечкенә автобус һәм бер педагог йөреп чыга дигән сүз. Әлеге хезмәттән эш сәгате көйсезрәк булган әти-әниләр бик теләп файдалана.

Чечняда, Грозныйда балалар – чып-чынлап яшәү мәгънәсе. Кичләрен шәһәр урамнарын тутырып ике ягына балаларының олысын-кечесен ияртеп йөргән әтиләргә (әниләр дә инде, әмма әниләр ул – гадәти күренеш) карап күңел сөенеп туймый. Сыра тотып ишек төбендә утыручы башка төбәк шәһәрләре түгел инде: монда мәсләк башка, куәс башка. Әнә шул эчкечелек булмаганга да бәрәкәт күптер, дип нәтиҗә ясыйм мин. Гаилә институты монда башка югарылыкта. Ә гаилә ул – үзе үк дәүләт.

Гөлнара ҖӘЛИЛОВА

Битлекле тормыш сабаклары

Бер ел да сигез айлап дәвам иткән битлекле тормыш безне күп нәрсәгә өйрәтте. Бигрәк тә үзе яки якыннарыннан берәрсе шул зәхмәт белән чирләгән, туганнарын-танышларын әлеге авыру алып киткән кешеләр тормышына, үз-үзенә, тормышка карашына күп үзгәрешләр кертте ул.

Югалтуларның күплегенә ияләнә, битараф кала торган булмады шул. Әмма әлегә кадәр бу авыруның барлыгына, аның зыян-зарарына ышанмаучылар, саклык чаралары күрмичә, башкаларны да куркыныч астына куючылар юк түгел. Монысы да хак. Гаиләләрендә берәр кешедә тест уңай булып та, битлек тә кими урамда, кеше арасында йөрүчеләрне күргәндә-ишеткәндә, аптырап та куясың.

– Бер көнне Казанга, Дәрвишләр бистәсендә яшәүче балаларыма барган идем. Кайтканда Балтачка йөрүче автобуска утырып кайттым. Автобус тулы кеше. Юл шактый озын бит, уйлана торгач, күңелгә шундый фикер килде. Карале, мин әйтәм, бу вакытта элегрәк бөтен кеше корык-корык йөткерә иде, көннәр бер җылытып, бер суытып уйный башласа, барыбызда шул хәл була иде, дим. Шыгрым тулы автобуста ник бер кеше йөткерсен! Мөгаен, хәзер күпләр, нәкъ безнең кебек, йөткерә башлауга чарасын күрәдер, уза киткәнче дип, дәвалана башлыйдыр, дим. Чыны шулай бит, өйдә үзебезме, балалармы аз гына йөткерә башласа, хәзер тамагын да чайкыйбыз, борынны да юдыртабыз, даруын да кабабыз. Үлән чәйләрен әйтеп тә тормыйм. Анысын без үзебез гомер-гомергә эчтек. Хәзер дә алардан башка булмый, – ди бер танышым. – Йөткерү димәктән, хәзер кеше башкалар алдында йөткерергә, төчкерергә дә курка бит. Шикләнмәсеннәр дисең инде. Бер тапкыр үзем дә нәкъ шул автобуска җитешим дип, урам буйлап бераз йөгереп барган идем, автобуска кереп утыруга, йөткерә башладым. Һич туктамый гына бит. Түзмәдем, автобустагыларга: «Курыкмагыз, авырмыйм мин, соңга калам дип йөгергән идем», – дип аңлатырга мәҗбүр булдым.

Үзем дә автобуста гына түгел, машинада да битлек киеп йөрим. Мин дә әлеге танышым кебек: «Авырый икән дип шикләнә күрмәгез, саклык өчен генә кидем», – дип әйтәм. Алай да кайбер танышлар: «Сал инде, Гөлсинә апа, шул битлегеңне. Юлда танып та булмый бит», – ди. Әмма күбесе шул авырмыйм дигән сүземне ишеткәч кенә сөйләшә башлый…

Их, бу битлексез тормышның кадерен белмәгәнбез икән, дигән чаклар күп була. Түземсезлек белән бу зәхмәтле чирнең чигенүен, бетүен көтәбез, дисәк тә, ялгыш та, ялган да булмас. Тик гомергә җитәрлек сабак алдыкмы икән – анысы гына сорау астында. Бераз вакыт үтүгә онытырбыз, элекке битараф тормышка әйләнеп кайтырбыз кебек тоела.

Бер начарның бер яхшысы була дигәндәй, бу ковид дигәнең дә бик күпләрдә иҗади сәләтләрне ачты кебек. Социаль челтәрләрдә бу темага күпме мәзәк, шигырь, такмаклар таралды. Шаяру катыш ачы хакыйкатьне, күңел кичерешләрен әдәби телгә күчерүчеләр дә шактый булды. Өлкәннәр әйткәндәй, ахыры хәерле булсын инде…

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Белми калмагыз!

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»ГА ЯЗЫЛУЧЫГА – МИНИ-ТРАКТОР

БҮЛӘКНЕ АЛУ ШАРТЛАРЫ

1 2022 елның беренче яртыеллыгына 6 айга «Ватаным Татарстан» газетасына язылырга.

2 Язылу квитанциясен безгә җибәрергә: «Ватсап» (89179270040) яки почта аша (420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт, «ВТ» газетасы редакциясе), яки электрон адреска (info@vatantat.ru).

БЕЛЕШМӘЛӘР ӨЧЕН ТЕЛЕФОН: 8-917-927-00-40

Җиңүче жирәбә юлы белән ачыкланачак. Квитанцияләр 2022 елның 16 гыйнварына кадәр кабул ителә, жирәбә 20 гыйнвар көнне үткәреләчәк.

Акцияне оештыручы: «Ватаным Татарстан» газетасы ДБУ, акцияне уздыру вакыты 2021 елның 1 ноябреннән 2022 елның 15 февраленә кадәр. Тулырак мәгълүмат vatantat.ru сайтында.

АКЦИЯНЕҢ ИГАНӘЧЕСЕ – «УРАЛЕЦ» СӘҮДӘ ЙОРТЫ

УРАЛЕЦ ТОРГОВЫЙ ДОМ МЫ ПРОДАЁМ НАДЁЖНОСТЬ

- ✓ мини-тракторлар;
- ✓ барлык төр тракторлар өчен запас частьлар;
- ✓ җир эшкәртү, чәчү, җыйнау өчен асылмалы җиһазлар.

Казан ш., Мамадыш тракты, 35А; Чаллы ш., Казан проспекты, 252/1; Әлмәт ш., Советская урамы, 42А.

ТЕЛЕФОННАР: 8-927-465-12-94, 8-987-931-55-50

ГАЗЕТАГА ЯЗЫЛУ ЫСУЛЛАРЫ



1 **ПОЧТА БҮЛЕКЧӘЛӘРЕНДӘ**

2 **ОНЛАЙН:** vatantat.ru **сайтындагы сылтама аша газетага язылу бик уңайлы һәм тиз. Программа үзе адымлап алып бара.**

Әлеге QR-код ярдәмендә телефон аша газетага язылырга һәм акча түләргә мөмкин.

Сөенечле хәбәр!

2022 елның беренче яртыеллыгы өчен 6 айга язылу бәяләре

П2435 атнага бер, җомга килә: ~~465 сум~~ 404,04 сум

П2409 Сишәмбе, чәршәмбе, җомга, шимбә килә: ~~1000,92 сум~~ 859,08 сум

6–16 декабрь көннәрендә ташламалы бәяләр!

Реклама 16+

40 ЕЛ ШӘЛ БӘЙЛӘҮЧЕ ИЛШАТ ЗАҺИДУЛЛИН:

«НАЧАР БУЛСА, КАБАРМЫЙ УЛ»

Балык Бистәсе районының Котлы Бөкәш авылында күршегә йөрү гадәте бетмәгән. Монда хәтта кич утырырга да йөриләр. Тик утырмыйлар, шәл бәйлиләр. Ә бу эш белән хатын-кызлар гына түгел, ирләр дә шөгыльләнә икән. Илшат Заһидуллинның кулына энә тота башлавына – 40 елга якын.

Без Заһидуллиннарга кергәндә, күршеләре дә җыелган иде. Тәберде Чаллысы авылында клубта сәнгать җитәкчесе булып эшләүче Илшат аларны утырмага дәшкән. Кичләрен бергәләп җырлашып, шәл бәйлиләр икән. Гаилә башлыгы мәктәптә театр түгәрәгe алып бара, шул ук вакытта хат таратырга да өлгерә. Клубта да кул эшләре белән шөгыльләнәләр. «Халкыбызның кул эшләре онытылмасын, кеше үз эченә бикләнеп яшәмәсен дип тырышу бу. Авылларда капка бикләп, бер-береңә хәл белешергә кермәү – матур күренеш түгел. Шау-гөр килеп, дус булып яшәүгә берни җитми», – ди 46 яшьлек Илшат Заһидуллин.

Күршеләре Гөлзәйнәп Мөхәммәтханова, Алсу Сәфәргалиева, Илшатның әнисе Фәүзия Ибраһимова энә энәләрен ничек кулда биетә! Күз иярми хәтта. Аларга Илшат кушыла, ул барысын да уздыра. «Күзне дә йомып бәйли алабыз, бәйләгән шәлләребез буа буарлык», – ди утырмага килүчеләр. Хатын-кыз өчен табигый кебек тоелса да, ирләрнең сәләте гаҗәпләндерә.

– Бу бит – хатын-кыз эше, дип төрттермиләрме, Илшат? – дип сорыйм аннан.

– Әйткәне әйтә инде. Оялып тормый. Бу минем өчен хобби түгел, чир кебек. Дөресрәге, бер бизнеска әйләнде дисәм дә була. Акчасы кергәч, шәлне бәйләп кенә торасы килә. Нервыларны да тынычландыра. Кирпеч заводында эшләгәндә дә, поездда барганда да вакытны бушка уздырмый идем. Машинада барганда да рәхәтләнеп бәйли алам. Машинаны хатын йөртә, – ди ул.

Илшат бу эш белән 6–7 яшьләрендә шөгыльләнә башлый. Башта әнисеннән качып энә тоткан, бәйләгәнен исә утын арасына яшереп барган. Без капчыкта озак ята алмый, кыскасы, сер, әлбәттә, ачылган һәм алар бергәләп бәйли башлаганнар. Илшат шәлләренең исәбен белми. Кечерәк шәл өчен – бер, зуррагына ике атна вакыт кирәк ди бит. Шуннан да күпме икәнлеген чамаларга мөмкин.

Шәл модадан чыкмый. Алучы булганда, бәйләүчесе дә бар. Бәйләгән әйберләрен Казанда танышлары да сатып бирә. Бүләккә алучылар да аз түгел. Бер шәлен 4–5 мең сумга сата. Сату – бер, ә менә аны рәхмәт әйтеп ябыну – икенче нәрсә. Кайчак, шәлем юньле булмады, дигән сүзләрне дә ишетергә туры килә. Шулай булгач, аны ничек итеп дөрес сайларга соң?

– Шәл сайлаганда кыллы була диючеләр дә очрый. Кылсыз булмый инде ул, яба-яба кылы коела, кабара бара. Начар булса, кабармый, – ди Илшат.

Монда ул 16 яшьтә Волгоград, Ростов шәһәрләренә мамыкка йөри башлаган вакытын искә төшерде. «Элек мамык башка булган. Мичнең морҗа астындагы буш урында куян асрадык. Йоны озын була, йолкып ала идек. Шуны бәрәннеке белән кушып бәйли идек. Мамыкланса, шәл бик әйбәт була иде».

Илдар Мөхәммәтҗанов

Шәлнең яхшы килеп чыгуы кәефкә карамый. Хуҗасы әйбәт булу кирәк. Холкы авыр кешегә аны бәйләү җиңел түгел икән. Илшат һәр эшен бисмилласын әйтеп, «җиңел кулдан булсын» дип башлый. Челтәрләре дә төрлечә килеп чыга. Бәйләгән вакытта күңеленә килгән бизәкләрне шәлгә «төшерә».

Илшат хатыны Галия белән ике бала тәрбияли. 22 ел бергә матур гомер кичерәләр. Гаилә башлыгы безгә гел елмаеп-көлеп кенә тора кебек тоелды. Үги әтисен мактап телгә алуы да сокландырды. «Ул мине тормышка, төпле булырга өйрәтте», – диде. Төпле булгач, гаиләсе дә, эше дә тотрыклы аның.

Сәрия МИФТАХОВА

ЗАТЛЫ МАТУРЛЫК

Оста

Балтач районының Бөрбаш авылында яшәүче блогер Альбина Фазлыева, үз кием коллекциясен булдырып, бер ел эчендә ике кибет ачты. Күңелендә күптәннән йөрткән теләге мөселман хатын-кызларын матур итеп киендерү була аның.

– Дәү әнием гомер буе тегү текте. Минем балачагым аның белән узды. Андагы иң матур сыйфатларны үземә алганмын мин. Хәер, безнең дәү әнинең килмәгән җире юк иде. Язмышы да аяныч булган аның. Ире бик иртә үлгәч, биш баланы ялгызы аякка бастыра ул. Бар юанычы тегү машинасы була. Ул кешеләргә заказга гына тегеп калмый, киемнәрне күпләп әзерләп, башка авылларга да барып сата. Гомере буе кешегә хезмәт итеп, алардан рәхмәт сүзләре ишетеп яшәде, – дип искә ала Альбина.

Оныгы да әбисе һөнәрен дәвам итә. Баштарак үз гаиләсенә, туганнарына, якыннарына тексә, соңрак социаль челтәрләрдә үз эшен халыкка күрсәтә башлагач, башка районнардан да сорап килә башлыйлар. Милли киемнәр сораучылар артып китә. Башта ул үзенең коллекциясен тегә. Бу киемнәрне халык шулкадәр ошата, күлмәкләр ике көндә сатылып бетә. Шуннан соң ире Алмаз, әти-әниләре белән киңәшеп, кибет ачарга булалар.

– Ике як әти-әни дә ризалык биреп, догалар укып торгач, күңелем тыныч, эшләр дә уңышлы бара, – ди ул. – Әмма иң зур терәгем – ирем. Алмаз кебек кеше башка юктыр. Хыялый хатын-кызлар күп ул. Аларның теләгән тормышка ашыручы ирләр сирәк. Алмаз миңа һәрвакыт ярдәм итә. Дөрес, «Инстаграм»га аның бар эшен төшереп куя алмыйм. Ул теләми. Бөтен кеше дә блогер булып бетә алмый бит инде. Без бар эшне бергә эшлибез. Хәтта күлмәкләргә чигәсе милли бизәкләрне дә ирем белән киңәшеп сайлыйбыз. Иремнең куллары алтын. Остаханәсендә әллә ниләр ясый. Тик моны кешегә күрсәтүне яратмый, кирәк санамый. Мин исә аның бу адымын хөрмәт итәм. Шуңа да аны бик төшермәскә тырышам.

Альбина беренче кибетен Балтачта ачты. Әлеге кибеткә Чүпрәледән, Ульян якларыннан да килүчеләр булган. Шуннан соң күңелләрендә тагын бер теләк туа. Ерак арадан килүчеләрне кызгана алар. Җитмәсә, алар килгәндә йә сайлаган күлмәкләренең башка төсе була, йә үлчәме җитми. Уйлашалар да Казанда кибет ачарга булалар. Монда инде хәтта Уфадан да килүчеләр бар икән.

– Бездә элек матур итеп киеним дисәң, ачык төсләрдәге күлмәкләр табып булмый иде. Аеруча мөселман кызларына кием сайлау мөмкинлеге булмады. Чит илләрдән кайткан капчык шикелле, кара төстәге киемнәр безгә туры килеп бетми. Шуңа да үзебезгә хас миллилекне саклап, башкачарак киемнәр тегәсе килде. Шөкер, күлмәкләрне яраталар. Сатып алучылар белән интернетта аралашам. Әлегә кадәр тискәре сүзләр әйтүче булмады. Күңелемне үсендереп, рәхмәт кенә укыйлар, – ди ул.

Альбина, кешене кием генә бизәми, аның күңеле чиста булырга, ул кеше әдәп-әхлакны белергә тиеш, дигән фикердә.

– Киемнәр сатуым акча өчен түгел. Безнең халык сыйфатка игътибар итә. Шуңа да иң яхшы тукымалар алам, иң оста тегүчеләрне табам. Иң мөһиме – ышанычны акларга, югалтмаска кирәк. Затлы кием кигән кеше үзен хөрмәт итәргә, башкалардан хөрмәт иттерергә тиеш дип саныйм. Моның өчен үрнәк булырга кирәк. Елмаеп, нур чәчеп, башкаларны үзенә тартып торырга тиешсең, – ди ул. – Мин кешеләргә рәхәтлелек бирүдән тәм табам. Үземне милләтемә хезмәт итәм дип саныйм. «Инстаграм»да татарча блог алып баруыма, хатын-кызларны матур итеп киендерә алуыма сөенәм. Күпләрнең ирләре дә, син шундый матурайдың, дип әйтә икән. Менә бит! Безнең хезмәт бушка китмәгән. Дөньядагы иң зур бәхет – кешеләргә хезмәт итү. Уйлап карагыз әле, кояш та хезмәттә. Ул да җирне яктырта. Без дә башкаларны сөендерүебезне дәвам итәргә тиеш.

Альбина, кешеләр белән ихлас, гади булырга кирәк, ди. Хәтта сатучыларына да: «Сез кием генә сатмыйсыз, кешегә матурлык өләшәсез, киңәшләрегез, елмаюыгыз өчен Аллаһы Тәгаләдән савап аласыз», – дип әйтеп куйган. Кибетләрдә татарча чиста итеп сөйләшүче кызлар эшли.

– Эшеңне бер җайга салгач, бар нәрсәгә дә өлгереп була. Иң мөһиме – теләк. Мин үз эшемне бик яратам. Күңелемә рәхәт, эштән ямь табам. Тормышка шөкер итеп туймаслык. Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт, – ди ул. – Хатын-кызларның матур итеп киенеп йөрүе күзне иркәли. Без үз күлмәкләребез белән татарларның нинди затлы икәнен дә күрсәтәбез. Киләчәктә дә милләткә хезмәт итеп яшәргә язсын!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7387 данә
Гомуми тираж – 17167 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 383

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+